**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУТЛУ-БУКАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422665, с. Кутлу-Букаш,
ул. Советская, дом 32

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КОТЛЫ-БӨКӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422665, Котлы-Бөкәш авылы,
Совет урамы, 32 нче йорт,

Тел.: (84361) 31521, факс: (84361) 31642, Kbuk.Rs@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 14 августы** **Котлы Бөкәш авылы** **№ _27__**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең 2017 елның 16 ноябрендәге 32 номерлы карары белән расланган 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга яраклаштыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, шәһәр округларының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» 2015 елның 1 октябрендәге 1050 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының « Котлы Бөкәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, карар бирәм::

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 16 ноябрендәге 32 номерлы карары белән расланган 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына (2018 елның 24 мартындагы 10 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

программа паспортында:

1.1) 7 юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле 8 юл өстәргә: «халыкны социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин итүнең максатчан күрсәткечләре (Индикаторлары)»:

| | |
|---|---|
| "Социаль инфраструктура объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү буенча планлаштырылган чараларның (инвестицион проектларның) киңәйтелгән тасвирламасы | 1. Котлы Бөкәш авылы «Дуслык» балалар бакчасында капиталь ремонт;<br>2. Котлы Бөкәш урта белем бирү мәктәбендә бассейн төзүне проектлау һәм төзү;<br>3. Тәберде Чаллысы һәм Мәмли Казак Чаллысы авылларында ФАП төзелеше<br>4. М-7 трассасына әйләнгеч юлны проектлау һәм төзү;<br>5. Шумбутка елгасы аша Сатлыган торак пунктына чыгучы күперне проектлау һәм төзү;<br>6. Котлы Бөкәш торак пунктында машиналар кую урыны проектлау һәм төзү;<br>7. Сатлыган торак пунктына баручы юлны проектлау һәм төзү;<br>8. Котлы Бөкәш җирлеге торак пунктларында су үткәрү линияләрен проектлау һәм төзекләндерү;<br>9. Котлы Бөкәш һәм Тәберде Чаллысы авылларында балалар уен мәйданчыклары урнаштыру;<br>10. Котлы Бөкәш җирлеге торак пунктларында урам-юл челтәрен үстерү, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау, капиталь ремонтлау. |

1.2) 8-10 юлларны 9-11 юллар белән санарга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы 34 йорт; Мәмли Казак Чаллысы авылы, Үзәк урам 29 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Г.Г.Нәҗипов
Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башлыгы